БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » апрель 2018 ел № 133

2018 елда Балтач муниципаль районы буенча эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарны, беренче тапкыр эш эзләүче башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, беренче тапкыр эш эзләүче башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны (алга таба - эшсез гражданнар) вакытлыча эшкә урнаштыруны 1 нче кушымта нигезендә оештырырга.

- эшсез гражданнарга туры килә торган эшне эзләү максатларында, оештырыла торган эшләрнең төрләре һәм аларны үткәрү тәртибе, шартлары, режимнары һәм хезмәт хакы турында, шулай ук әлеге эшләрне башкарганда оешмалар тарафыннан бирелә торган ташламалар турында халыкка, шулай ук «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ндә теркәлгән затларга хәбәр итәргә;

- эш бирүчеләр белән эшсез гражданнарның вакытлыча мәшгульлеген оештыру турында шартнамәләр төзергә.

2. Эш бирүчеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ белән эшсез гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамәләр төзергә;

- «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән вакытлы хезмәт килешүләре төзергә;

- эшсез гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамәмә нигезендә оештырылган эш урыннарында гражданнарның мәшгульлеген тәэмин итәргә.

3. «2017 елда Балтач муниципаль районы буенча эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында» 2017 елның 20 апрелендәге 141 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныгга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров